ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ Казан шәһәре Боерык

29.09.2022 № 350-од

«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 07 июнендәге145-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында

боерам:

1. «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 07 июнендәге145-од номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 392-од номерлы, 2020 елның 27 апрелендәге 125-од номерлы, 2020 елның 05 ноябрендәге 338-од номерлы, 2021 елның 02 июнендәге 161-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 257-од номерлы, 2021 елның 23 сентябрендәге 288-од номерлы, 2022 елның 07 апрелендәге 79-ое номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуладагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010

елның 02 ноябрендәге 880 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Биологик төрлелек бүлеге башлыгына Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында Административ регламентны урнаштырырга.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хокукый тәэмин итү буенча әйдәп баручы киңәшчегә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.».

2. Күрсәтелгән боерык белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне рәис урынбасары Р.Г. Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының 2022
елның 29 сентябрендәге
350-од номерлы боерыгы
белән расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 07 июнендәге 145-од боерыгы белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр:

I бүлектәге 1.2 пунктның икенче абзацында эш итә» сүзен «эш итә ала» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлектә:

2.3 пунктының алтынчы абзацында «шәхси кабинет» сүзләрен «шәхси кабинетта» сүзләренә алмаштырырга;

2.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, гариза бирүче мөстәкыйль тапшыра торган документлар:

1. Объектны файдалануга тапшыруга Рөхсәт бирү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

2. Объектны файдалануга тапшыруга Рөхсәт бирү турындагы гаризага түбәндәге документларны беркетергә кирәк:

1) капиталь төзелеш объектын кабул итү акты (төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә төзелеш, реконструкция гамәлгә ашырылган очракта);

2) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документларына (проект документларының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү өлешендә (алга таба – РФ ШтК), шул исәптән, энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килүен раслый торган һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат (төзелеш, үзгәртеп кору төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә тормышка ашырылган очракта –төзелешне башкаручы зат, төзүче яки техник заказчы, шулай ук, шартнамә нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашырган очракта – төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат) тарафыннан имзаланган акт;

3) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт (әлеге объектны мондый тоташтыру (технологик тоташтыру) проект документлары белән каралган очракта);

4) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының урнашуын, җир кишәрлеге чикләрендә инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен һәм җир кишәрлеген планлаштыручы оешманы чагылдыручы һәм төзелешне башкаручы зат (төзүне башкаручы зат, төзүче яки төзелеш подряды килешүе нигезендә төзелеш,

үзгәртеп кору алып барган очракта – техник заказчы) тарафыннан, линияле объектны төзү, үзгәртеп кору очракларыннан тыш, имзаланган схема;

5) куркыныч объекттагы авария нәтиҗәсендә зыян китергән өчен куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә куркыныч объекттагы авария нәтиҗәсендә зыян салган өчен куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү килешүе төзүне раслый торган документ;

6) әлеге объектка үзгәртеп кору, консервацияләү, ремонт үткәргәндә һәм аны заманча файдалану өчен җайлаштырганда, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкярләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән, мәдәни мирас объектларын саклау буенча тиешле орган тарафыннан расланган мәдәни мирас объектларын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты.

7) «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә әзерләнгән капиталь төзелеш объектының техник планы;

8) Гариза бирүченең шәхесен яки Гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслый торган документ (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә). Республика порталы яисә Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, шәхесне раслый торган документтан алынган белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – ЕСИА) хисап язмасын раслаганда тикшерелә;

9) Гариза бирүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, Гариза бирүче вәкиленең Гариза бирүче исеменнән эш итәргә вәкаләтләрен раслый торган документ.

10) төзүче һәм, бинаны, корылманы төзүне яки үзгәртеп коруны финанслау бурычы башка затка (башка затларга) йөкләнгән очракта, башка зат (башка затлар) арасында төзелгән, төзүче һәм (яки) башка затның (башка затларның) төзүче һәм (яки) башка затның (башка затларның) төзелгән, үзгәртеп корылган бинага, корылмага яки мондый бинада урнашкан барлык бүлмәләргә, корылмаларга, машина урыннарына милек хокукы барлыкка килүне күздә тота торган шартнамә яисә шартнамәләр, шулай ук төзүче һәм башка затның (башка затларның) әлеге шартнамәләр буенча йөкләмәләренең үтәлешен раслый торган һәм күрсәтелгән затның (күрсәтелгән затларның) әлеге өлештә каралган объектларга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыруга ризалыгын үз эченә алган документлар (бинаны, корылманы төзү, үзгәртеп кору башка затлар акчаларын җәлеп итеп башкарылган очракта).

10 нчы пунктта күрсәтелгән документлар түбәндәге очракларда җибәрелми:

төзү, үзгәртеп кору «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ

номерлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп башкарылган күпфатирлы йортны яки башка күчемсез милек объектын, торак-төзелеш кооперативы тарафыннан төзелгән, үзгәртеп корылган күпфатирлы йортны файдалануга тапшырганда;

капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза белән төзүче мөрәҗәгать иткән вакытка төзүче һәм РФ ШтК ның 55 статьясындагы $3^6$ өлешендә күрсәтелгән башка зат (башка затлар) арасында төзелгән, үзгәртеп корылган бинага, корылмага яисә мондый бинада, корылмада урнашкан бүлмәләргә, машина урыннарына хокуклар барлыкка килү турында килешүгә ирешелмәгән очракта.

РФ ШтК ның 55 статьясындагы $3^6$ – $3^9$ өлешләрендә каралган таләпләр 2022 елның 01 сентябренә кадәр бирелгән гаризаларга кагылмый.

«Территорияләрне планлаштыру буенча документларны, җир кишәрлекләренең килештерү, раслау, гамәлдә булу вакытын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 02 апрелендәге 575 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 575 номерлы карары) нигезендә 2023 елның 1 гыйнварына кадәр әлеге пунктның 1, 2 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми.

Әлеге пунктның 1 – 4 пунктчаларында күрсәтелгән документларны, күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагында булмаса, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә җибәрә, Әгәр әлеге абзацта күрсәтелгән документлар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмалар карамагында булса, мондый документларны, гариза бирүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль тапшырмаган очракта, күрсәтелгән документлар алар карамагында булган органнардан һәм оешмалардан Комитет соратып ала.

Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документлар капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның тиешле этабына караган өлешендә рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән очракта капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата элек бирелгән Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр турында белешмәләр күрсәтелә (булган очракта).

Әгәр объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада күрсәтелгән булса, Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең дубликатын бирү өчен, гариза бирүче Комитетка әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендәге форма буенча Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең дубликатын бирү турында язма гариза җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен, Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең дубликатын бирү турында гариза бланкларын гариза бирүче Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм беркетеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып җибәрелергә мөмкин:

1) Комитетка шәхсән яисә почта аша кәгазьдә һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

2) КФҮ аша кәгазьдә һәм 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә.

Гариза биргәндә, гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәлү номеры һәм электрон гариза бирү датасы булган КФҮ дән расписка бирелә;

3) Республика порталы, Бердәм портал аша электрон документ рәвешендә.

Гаризага, шул исәптән ышаныч кәгазьләренә беркетелгән электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә.

Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталындагы, Бердәм порталдагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

Гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, гариза бирүчеләр гаризага гади электрон имза салалар.

Гади электрон имза алу өчен, гариза бирүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын үтәргә, шулай ук хисап язмасын стандарттан түбән булмаган дәрәҗәдә расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затлар вәкилләре, гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргәндә, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Соратуны Республика порталы, Бердәм портал аша биргәндә, гариза бирүче документларның электрон образларын яисә 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларны электрон рәвештә тапшыра.

Гариза бирүченең шәхесен билгеләү шәхсән кабул итү барышында Россия Федерациясе гражданы паспортын яисә шәхесен раслый торган башка документны күрсәтү юлы белән, Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә идентификация һәм аутентификация ярдәмендә Комитетта, КФҮдә, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның $14^1$ статьясындагы 18 өлешендә каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып гамәлгә ашырыла.

2.6.2 пунктында:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының (РФ ШтК 54 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган очракта) РФ ШтК 49 статьясының 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә туры килү-килмәве турында бәяләмәсе (шул исәптән эш документларына кертелгән һәм РФ ШтК 52 статьясының $1^3$ өлеше нигезендә мондый проект документларының бер өлеше булган үзгәрешләрне исәпкә алып), федераль башкарма хакимият органының федераль дәүләт экологик күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вәкилнең РФ ШтК 54 статьясының 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган бәяләмәсе.

Күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) Күчемсез милеккә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрында булмаган очракта, җир кишәрлегенә хокукны билгели торган документлар гариза бирүче (төзүче) тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә.

Документларны алу ысуллары һәм гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларны тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.6.1 пункты белән билгеләнгән.

Гариза бирүче гариза биргәндә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алырга мөмкин булган документларны мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзалары белән расланган электрон документлар рәвешендә мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән документларны тапшырмау гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2023 елның 1 гыйнварына кадәр әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән документны бирү РФ Хөкүмәтенең 575 номерлы карары нигезендә таләп ителми.»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге

Дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү бердәм вариантта башкарыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән; дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерылып торган дәүләт хезмәте күрсәтүнең аерым сценарийлары юк.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү вариантлары исемлеге, шул исәптән мондый дубликат бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликатын бирү бердәм вариантта башкарыла һәм бирү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дубликат бирү өчен кирәкле документлар исемлеге белән; дубликат бирү нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерылып торган сценарийлары юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчегә бирелгән документның дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигез юк.

3.3. Гариза бирүчене профильләштерүнең административ процедурасы тасвирламасы

Гариза бирүчене профильләштерү процедурасы башкарылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдәге гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән гариза язу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү яки баш тарту турында хәбәрнамә бирү:

а) Комитетка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән рәсми почтага ojm@tatar.ru электрон документ формасында), КФҮдән, Республика порталыннан, Бердәм порталдан алынган документларны һәм гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү;

в) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү;

г) гариза бирүчегә Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү яки баш тарту турында хәбәрнамә бирү:

3) техник хатаны төзәтү:

а) техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

б) объектны файдалануга тапшыруга яңадан рәсмиләштерелгән Рөхсәтне әзерләү;

в) гариза бирүчегә объектны файдалануга тапшыруга яңадан рәсмиләштерелгән Рөхсәт бирү;

4) Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын әзерләү, бирү яки бирүдән баш тарту:

а) Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең дубликатын бирү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын яисә Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту дубликатын әзерләү;

в) гариза бирүчегә Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын яки Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә бирү.

3.5. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза язу өлешендә ярдәм күрсәтү;

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) почта аша (шул исәптән

электрон) дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен документлар формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Бүлек белгече, кирәк булганда, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм итә.

Гариза бирүче Комитетка шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) электрон хәбәр рәвешендә, почта аша кәгазь чыганакта, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталының интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru) дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерүдә консультация алу өчен мөрәҗәгать итә.

Гариза бирүче КФҮгә дәүләт хезмәте күрсәтүне алу тәртибе турында консультация алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итә ала.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутырырга ярдәм итә.

Гариза бирүче КФҮ сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru/) ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала.

Шулай ук Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында Республика порталында, Бердәм порталда консультация алырга хокуклы.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.6. Гариза бирүчегә Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт яки Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә бирү.

3.6.1. Гариза комитетка шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта, Республика порталы, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүче гариза һәм документларны электрон формада Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика Порталында, Бердәм порталда авторизация үтә;

Республика порталында, Бердәм порталда электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын (кирәк булганда) электрон гариза формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы куя);

тутырылган электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

КФҮ аша гариза биргән очракта:

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм документларны әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә КФҮгә тапшыра.

Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, КФҮ белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта).

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, КФҮ белгече гариза бирүченең кабул ителгән һәм теркәлгән документларын КФҮнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедуралар КФҮнең эш регламенты һәм Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү белән билгеләнгән вакытта, ләкин КФҮдә гаризаны теркәгәннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән гариза.

3.6.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

кергән документларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада кушып бирелгән документларны һәм документларның электрон образларын өйрәнә;

электрон документ образларының комплектлылыгын, укылуын тикшерә;

Республика порталына, Бердәм порталга мөрәҗәгать итеп, электрон имзаның чынбарлык шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган очракта);

гариза бирүче вәкаләт биргән зат буларак эш итүче гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның булу-

булмавын тикшерү;

документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында тамга белән гариза күчермәсен гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрү.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта, Бүлек белгече Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризаларны теркәү журналына (алга таба – Журнал) мәгълүматлар кертә.

Журналда түбәндәгеләр күрсәтелә:

гариза бирүче тарафыннан документлар тапшыру датасы (Комитетка документлар керү датасы);

гариза бирүченең исеме

документларны кабул иткән структур бүлекчәнең вазыйфаи затының фамилиясе һәм инициаллары;

объектның исеме һәм кергән документларның (папкалар, тартмаларның һ. б.) исемлеге;

гариза бирүчегә Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирелү (объектны эксплуатациягә тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту) датасы яки почта аша җибәрелгән дата.

Журнал кульязма һәм электрон формаларда алып барыла (әлеге Регламентка 7 нче кушымта нигезендә).

Әлеге Регламентта күрсәтелгән процедураны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Комитетта гариза һәм документлар теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кабул ителгән һәм теркәлгән документлар.

3.6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү.

Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны тапшырган очракта, Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарга, дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынган муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарга, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән исемлек нигезендә мәгълүмат алу өчен соратулар җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү.

Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән соратулар нигезендә соратыла торган документларны (мәгълүматны) тапшыралар яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамәләр җибәрәләр.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органнар законнар белән билгеләнгән вакытта әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыралар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән соратуларга җаваплар яки мәгълүмат җитмәү турында хәбәрнамә.

3.6.4. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт яки баш тарту турында хәбәрнамә әзерләү:

Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

документларның әлеге Регламентның 2.6.1 пункты таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерүне гамәлгә ашыра;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигез булу (булмауны) билгели;

Бүлек белгече гариза бирүчедән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнардан кергән документлар нигезендә түбәндәгеләрне башкара:

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт яки баш тарту турында хәбәрнамә әзерли;

Объектны эксплуатацияләүгә тапшыру өчен рөхсәтне яки баш тарту турында хәбәрнамәне Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

